

26 сентябрьдә Темников районы Лесное Цибай авылында жиденче тапкыр vтә торган «Цибайча кәбестә» гастрономия фестивалендә Мордовия һәм башка кvрше районнардан килгән кунаклар район территориясендә яшәvче халыкларнын милли ризыкларын һәм эчемлекләрен дегустацияләv ярминкәсе һәм, әлбәттә, жирле осталарнын сувенирлары каршы алды.

Мордваларнын борынгы кәбестә кисv һәм тозлау йоласы бәйрәмнен берсенә әверелде. Бәйрәм программасы тыгыз булды: анда башка милләт халык жыр ансамбльләре белән беррәттән «Агыйдел» чыгышлары белән тамашачынын кvнелен кvтәрделәр. Бу конне тагы торле такмак лар, шигырьләр, әйтемнәр янгырады. Чарада мастер-класслар, конкурслар, приз лар, бvләкләр- балалар да, ол-кәннәр дә уеннар га һәм конкурсларга шатланып кушылдылар.



Темников райо ны татарлары әлеге бәйрәмдә активларнын берсе булдылар. Мә-сәлән, Тархан, Митрял, Урей, Ишейка һәм башка авыл китапханәчеләре «Цибайча кәбестәләр» район гастрономия фестивалендә татар милли ашлары һәм татар йорты белән катнашты. Бу чынлап торле милләтне берләштерә, бер-берсенен мәдәниятын баета торган ча-ра. Шуна дәлил итеп Ишейкида яшәгән русслар, мукшылар, татарлар очен хезмәт иткән китапханә житәкчесе Татьяна Сергеевна Кузнецованын пәрәмәчләре. Ул:
- Бу фестиваль ризык турында гына тvгел, традицияләр, кеше кулларынын жылысы турында да. Мастер-класслар, ашамлыкларны татып карау, балалар очен активлык, музыкаль чыгышлар бары тик жылы кvнел хатирәләре генә калдырды. Мин дә бәйрәмдә катнаштым. Кырык бер ел татарлар белән Ишейки авылында тату яшибез. Үзебезнен авыл этно-йортында кvрше Сания апа Еникеева ойрәткән рецепт буенча татар пәрәмәчләрен пешердем, бик тиз сатып та бетердем. Татар пәрәмәчләре биляшлардан пешерv рецепты, пешv ысулы белән аерылып тора: акмай кvләме, йомыркасы һәм конбагыш маенда конбатыш татарларыныкыча батырып пешvе ашамлыкны тагы да тәмле итә.
Чарада пешкән кәбестә, шурпа, мордва коймагы (пачат), vлән чәе, колак, пәрәмәч... - балачак хатирәсе кебек. Бу бәйрәмне жылылык һәм мә-дәният белән уртаклашу кичәсе дип тә атарга момкин.

Наилә НАСЫРОВА